**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-667 номерлы, 2013 елның 7 маендагы ПУ-385 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1144 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы, 2015 елның 22 маендагы ПУ-473 номерлы, 2016 елның 30 гыйнварындагы ПУ-67 номерлы, 2016 елның 25 июнендәге ПУ-550 номерлы, 2016 елның 12 августындагы ПУ-685 номерлы, 2016 елның 20 октябрендәге ПУ-948 номерлы һәм 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) III кисәкнең атамасында «ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛЕ ОРГАННЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫНА БӘЯЛӘМӘСЕН КАРАУ» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ бүлек өстәргә:

**«$12^1$ бүлек. Вәкаләтле органның Татарстан Республикасы Президенты указына бәяләмәсен карау тәртибе**

$12^1$.1. Вәкаләтле органның «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты указына уздырылган экспертиза турында бәяләмәсе (алга таба – бәяләмә) әлеге бәяләмәне алган көннән 10 эш көне дәвамында карап тикшерелә.

$12^1$.2. Татарстан Республикасы Президенты яисә Аппарат Җитәкчесе кушуы буенча бәяләмә Эксперт департаменты һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле

вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге белән берлектә Дәүләт-хокук идарәсе тарафыннан карап тикшерелә. Кирәк булганда бәяләмәне карап тикшерүгә Аппаратның башка кызыксынган структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары җәлеп ителә.

$12^1$.3. Бәяләмәдә бирелгән нәтиҗәләр белән килешкән очракта, Аппарат Җитәкчесе тарафыннан нигезсез рәвештә эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге алып баруга комачаулык итүче Татарстан Республикасы Президенты указына яисә аның аерым нигезләмәләренә үзгәрешләр кертүне яисә аларны үз көчен югалткан дип тануны күздә тотучы указ проектын әзерләү буенча эш оештырыла.

Бәяләмәдә бирелгән нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, Аппарат Җитәкчесе тарафыннан вәкаләтле органга әлеге нәтиҗәләргә каршы дәлилләр бәян ителгән нигезле җавап юллана.

Вәкаләтле органга җавап Дәүләт-хокук идарәсе тарафыннан әлеге Регламентның $12^1$.1 пунктында күрсәтелгән срокларда әзерләнә.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты * Аппарат Президента Республики Татарстан
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 04 июнь
№ ПУ-402